**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең Имәнле-Бортас торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

24 октябрь, 2019 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең Имәнле-Бортас торак пунктында граждannар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең Имәнле-Бортас авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

а) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

б) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:

- материаллар сатып алып зиратларны чистарту һәм төзекләндерү3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

· 4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кече Мәми авыл җирлеге башлыгы Е.Н. Алексеева